8. Гавами тыңлаулар үткәрү йомгаклары буенча тәкъдимнәр кабул ителә, алар гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проектын кабул итү компетенциясенә кертелгән җирле үзидарә органнары һәм авыл җирлегенең вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.

9. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларны дәлилләп нигезләүне дә кертеп, гавами тыңлаулар уздырганнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча, әгәр гамәлдәге законнарда башка срок каралмаган булса, бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

10. Гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана торган норматив хокукый акт белән билгеләнә.

11. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияләрне благанлау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тотучы проектлар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, рөхсәт ителгән капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның икенче төренә үзгәртү

мәсьәләләренә җирдән файдаланунын һәм төзелешнең расланган кагыйдәләре булмаганда җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып, авыл җирлеге Уставы һәм (яисә) авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

## 21 маддә. Авыл җирлеге гражданнары җыелышы

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикер алышу, халыкка җирле үзидарә органнары һәм авыл җирлеге җирле үзидарәсе вазыйфаи затлары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү, инициатив проектларны кертү һәм аларны карау, авыл җирлеге территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча фикер алышу өчен гражданнар җыелышлары үткәрелергә мөмкин. Гражданнар җыелышлары микрорайоннар, торак массивлар, кварталлар, урамнар, торак йортлар буенча чакырыла.

2. Гражданнар җыелышы халык, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге башлыгы инициативасы буенча, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставында каралган очракларда үткәрелә.

3. Авыл җирлеге Советы яки авыл җирлеге башлыгы инициативасы белән үткәрелә торган гражданнар җыелышы тиешле авыл җирлеге Советы яки авыл җирлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә.

4. Халык инициативасы белән уздырыла торган гражданнар җыелышы авыл җирлеге Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының, тиешле территориядә яшәүче һәм җыелышта катнашырга хокуклы халык санының кимендә 10 процентын тәшкил иткән гражданнар төркеменең, шул территорияләрдә урнашкан предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренең язма тәкъдиме буенча билгеләнә.

Гражданнар җыелышын уздыру турындагы тәкъдимдә аның каравына чыгарыла торган мәсьәләләр исемлеге, җыелышны уздыруның тәкъдим ителә торган вакыты һәм урыны булырга тиеш. Тәкъдимгә вәкаләтле затлар, ә җыелыш үткәрү инициативасы белән гражданнар төркеме мөрәҗәгать итсә, аларның һәркайсының фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган көнен, яшәү урынының адресын күрсәтеп, әлеге гражданнар имза салырга тиеш.

Авыл җирлеге советы якындагы утырышында гражданнар җыелышын үткәрү турындагы тәкъдимне карый.

Авыл җирлеге Советы гражданнар җыелышын үткәрүдән аның максатка ярашлы булмавы сәбәпләре буенча баш тартырга хокуклы түгел.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм уздыру тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

6. Гражданнар җыелышын үткәрү вакыты һәм урыны турында һәм фикер алышуга кертелә торган мәсьәләләр турында тиешле территориядә яшәүчеләргә җыелыш уздыру көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларыннан, почта хәбәрләреннән, фатир саен (ишегалды) әйләнеп чыгулардан, белдерүләрдән һәм башка мөмкин булган чаралардан файдаланып хәбәр ителә.

Гражданнар җыелышын әзерләүне һәм уздыруны авыл җирлеге Башкарма комитеты тәэмин итә.

7. Җыелышлар эшендә шушы территориядә яшәүче, сайлау хокукына ия гражданнар катнашырга хокуклы. Җыелышта катнашу хокукы булган гражданнарның гомуми саны Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны һәм яшәү урыны буенча муниципаль сайлаулар уздырганда файдаланыла торган Россия Федерациясе гражданнарын теркәп исәпкә алу күрсәткечләре нигезендә билгеләнә.

Әгәр җыелышта катнашырга хокуклы гражданнар санының кимендә өчтән бере катнашса, гражданнар җыелышы тулы хокуклы дип санала.

Җыелыш карарлары җыелышта катнашучы гражданнарның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

8. Гражданнар җыелышы җирле үзидарә органнарына һәм авыл җирлеге җирле үзидарәсенең вазыйфаи затларына мөрәҗәгатьләр кабул итәргә, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм авыл җирлеге җирле үзидарәсенең вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрдә гражданнар җыелышын тәкъдим итәргә вәкаләтле затларны сайларга мөмкин.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча уздырыла торган гражданнар җыелышы территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карар кабул итә.

10. Гражданнар җыелышы тарафыннан кабул ителгән мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгатьләрдәге мәсьәләләрне хәл итү компетенцияләренә кертелгән җирле үзидарә органнары һәм авыл җирлеге җирле үзидарәсе вазыйфаи затлары тарафыннан язма җавап җибәреп, мәҗбүри каралырга тиеш.

11. Гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе, шулай ук гражданнар җыелышының вәкаләтләре федераль закон, әлеге устав һәм авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты, территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

12. Гражданнар җыелышы йомгаклары ул уздырылганнан соң бер ай эчендә рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

## 22 маддә. Авыл җирлеге гражданнары конференциясе (делегатлар җыелышы)

1. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм авыл җирлегендә яшәүче барлык кешеләрнең фикерен ачыклау кирәк булган очракта үткәрелә. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) авыл җирлегенең тиешле территориаль өлешләрендә яшәүче гражданнар җыелышын чакыру кыен булган, шул исәптән тиешле территориядә яшәүче һәм гражданнар җыелышында катнашу хокукы булган халык саны 100 кешедән арткан очракларда үткәрелә.

2. Гражданнар конференциясен (делегатлар җыелышын) билгеләү һәм үткәрү, делегатлар сайлау тәртибе әлеге устав, авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты, территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

3. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышы вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

4. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) халык, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге башлыгы инициативасы белән үткәрелә. Авыл җирлеге Советы яки авыл җирлеге башлыгы инициативасы белән үткәрелә торган гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) тиешенчә авыл җирлеге Советы яки авыл җирлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә. Халык инициативасы белән үткәрелә торган гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә.

5. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы), әгәр анда гражданнар җыелышларында сайланган һәм тиешле территориядә яшәүче уналты яшькә җиткән кешеләрнең кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы дип санала. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышлары) карарлары конференциядә катнашучы делегатларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

6. Гражданнар конференциясенең (делегатлар җыелышының) йомгаклары ул уздырылганнан соң бер ай эчендә рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

## 23 маддә. Авыл җирлеге гражданнар җыены

1. Гражданнар җыены халыкның җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу рәвеше булып тора.

2. Гражданнар җыены "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законда каралган очракларда һәм

"Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында" гы нигезләмәгә ярашлы рәвештә Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Советы тарафыннан үткәрелә.

3. "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсендә каралган очракларда гражданнар җыены уздырылырга мөмкин:

1) составына күрсәтелгән торак пункт кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча торак пунктта күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүгә китерә торган җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

2) җирлек составына керүче торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча;

3) авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын күрсәтү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

4) авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс уздырганда муниципаль хезмәт турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатларында уздырылырга мөмкин.

4. Гражданнар җыены муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан йә сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләрнең кимендә 10 кешедән торган төркеме инициативасы белән чакырылырга мөмкин.

5. Җыенны уздыру инициативасын хуплап җыярга кирәкле имзалар саны сайлау хокукына ия, торак пункт территориясендә даими яисә күбесенчә яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санының 5 процентын тәшкил итә, әмма 25 имзадан да ким була алмый.

6. Муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлек башлыгы карары белән билгеләнә, инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән билгеләнә.

7. Торак пунктта яшәүчеләргә гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр ителә, "Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында"нигезләмәдә билгеләнгән

тәртип нигезендә муниципаль хокукый акт проекты һәм гражданнар җыены карарына чыгарыла торган мәсьәләләр буенча материаллар белән алдан ук таныштырыла.

8. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып торалар, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

9. Әлеге маддәдә каралган гражданнар җыены анда сайлау хокукына ия торак пунктта яисә җирлектә яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы. Әгәр торак пунктта әлеге торак пунктта сайлау хокукына ия халыкның яртысыннан артыгының бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, гражданнар җыены әлеге Устав нигезендә гражданнар җыенын уздыру турында Карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да артмаган вакытта этаплап үткәрелә. Моңа кадәр гражданнар җыенында катнашкан затлар алдагы этапларда тавыш бирүдә катнашмый. Гражданнар җыены карары өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыграгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала;

10. Гражданнар җыены торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирлек составына керүче торак пункт территориясендә үткәрелергә мөмкин.

Гражданнарның мондый җыены торак пункт территориясенең тиешле өлешендә яшәүче кимендә 10 кешедән торган төркем инициативасы белән җирлек Советы тарафыннан чакырыла.

Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясе чикләре, җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә туры килә торган хәл итүдә торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләренең уртаклыгы критерийларыннан чыгып, җирлек Советы карары белән билгеләнә".

### 24 маддә. Авыл җирлеге гражданнарыннан сораштыру

1. Гражданнардан сораштыру җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары карарлар кабул иткәндә халыкның фикерен ачыклау һәм исәпкә алу өчен авыл җирлегенең бөтен территориясендә яисә территориясенең бер өлешендә үткәрелә.

Сораштыру нәтиҗәләре рекомендация характерында.

2. Гражданнардан сораштыруда сайлау хокукына ия авыл җирлеге халкы катнаша ала. Инициатив проектны хуплау турында гражданнарның фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча гражданнардан сораштыруда муниципаль берәмлекнең

яисә аның инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган өлешендә уналты яшькә җиткән кешеләр катнашырга хокуклы.

3. Гражданнардан сораштыру инициативасы буенча үткәрелә:

1) авыл җирлеге Советы яисә авыл җирлеге башлыгы - җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының - авыл җирлеге җирләренең республика һәм республикаара әһәмияттәге объектлар өчен максатчан билгеләнешен үзгәртү турында карарлар кабул иткәндә гражданнар фикерен исәпкә алу өчен;

3) инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлек яисә аның өлешендәге уналты яшькә җиткән кешеләр - әлеге инициатив проектны хуплау турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.

4. Гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

5. Гражданнардан сорашып белешүне билгеләү турында карар авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнардан сораштыру үткәрү өчен Лаеш муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан түбәндәге веб-адрес буенча файдаланырга мөмкин: http://laishevo.tatarstan.ru. Гражданнардан сорашып белешүне билгеләү турында авыл җирлеге Советы карарында түбәндәгеләр каралган:

1) сораштыруны үткәрү датасы һәм сроклары;

2) сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауны (сорауларны) формалаштыру;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазенең формасы;

5) сораштыруда катнашучы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең минималь саны;

6) гражданнардан муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сораштыру үткәрелгән очракта сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.

6. Авыл җирлегендә яшәүчеләргә гражданнардан сорашып белешү уздыру турында уздырылырга кимендә 10 көн кала хәбәр ителә.

7. Гражданнардан сораштыру әзерләүгә һәм уздыруга бәйле чараларны финанслау гамәлгә ашырыла:

1) авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән – авыл җирлеге җирле үзидарә органнары яисә муниципаль берәмлек халкы инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә - Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән.

8. Сораштыру нәтиҗәләре сораштыру уздырылганнан соң бер ай эчендә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Сораштыру нәтиҗәләре белән авыл җирлегендә яшәүче теләсә кайсы кеше танышырга хокуклы. Сораштыру нәтиҗәләре авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тиешле карарлар кабул иткәндә исәпкә алынырга тиеш.

**25 маддә. Авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аеруча мөһим мәсьәләләре буенча халык фикер алышуы**

1. Муниципаль хокукый актлар проектларын һәм җирле әһәмияттәге башка аеруча мөһим мәсьәләләрне халык фикер алышуына чыгару турындагы карар авыл җирлеге Советы тарафыннан үз инициативасы буенча яисә тиешле территориядә яшәүче гражданнар таләбе буенча авыл җирлеге Советы билгеләгән тәртиптә кабул ителә.

2. Муниципаль хокукый акт проектының тексты һәм халык фикер алышуына чыгарыла торган мәсьәләләр буенча башка материаллар, аларны халык фикер алышуына чыгару турында карар кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла, авыл җирлегендә яшәүчеләргә таратыла, халык белән танышу өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, башка ысуллар белән халыкка җиткерелә.

3. Мәсьәләне халык фикер алышуына чыгару белән бер үк вакытта авыл җирлеге Советы фикер алышу барышында керә торган тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне карау эшен оештыру срогын һәм тәртибен билгели, күрсәтелгән максат өчен махсус комиссия төзи.

4. Авыл җирлеге Советы үзе чыгара торган муниципаль хокукый актлар проектлары һәм җирле әһәмияттәге башка мөһим мәсьәләләр буенча фикер алышуны тәэмин итә, моның өчен тиешле шартлар тудыра.

5. Халык фикер алышуына чыгарылган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр авыл җирлеге Советына җибәрелә.

6. Муниципаль хокукый актлар проектлары һәм җирле әһәмияттәге башка мөһим мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр авыл җирлеге Советы тарафыннан карала.

7. Халык фикер алышуы нәтиҗәләре турында халыкка хәбәр ителә.

**26 маддә. Авыл җирлегенең Иҗтимагый (консультатив) советлары**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча карарлар эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда халыкның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру максатларында гражданнарның һәм авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү өчен авыл җирлегенең Иҗтимагый советы төзелә.

2. Авыл җирлегенең Иҗтимагый советы аның эшчәнлегендә авыл җирлегендә яшәүчеләрнең, иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар вәкилләренең ирекле катнашуы нигезендә төзелә.

3. Авыл җирлеге Иҗтимагый советын булдыру тәртибе, вәкаләтләре, аның утырышларын үткәрү һәм карарлар кабул итү тәртибе, авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының мәгълүмат бирүгә, консультацияләүгә һәм авыл җирлеге Иҗтимагый советы эшчәнлегенә ярдәм итүнең башка мәсьәләләренә карата хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы, аны тарату процедурасы, шулай ук аны оештыруның һәм эшчәнлегенең башка мәсьәләләре авыл җирлеге Советы раслый торган нигезләмәдә билгеләнә.

4. Башка Иҗтимагый (консультатив) советлар авыл җирлеге җирле үзидарә органнары каршында аларның карарлары нигезендә төзелергә мөмкин.

5. Иҗтимагый (консультатив) советларда эш иҗтимагый башлангычларда алып барыла.

**27 маддә. Гражданнарның авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгатьләре**

1. Гражданнар авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына индивидуаль һәм күмәк мөрәҗәгатьләргә хокуклы.

2. Гражданнар мөрәҗәгатьләре "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль Законда, "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында"2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда каралырга тиеш.

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен һәм срокларын бозган өчен җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы булалар.

### 28 маддә. Авыл җирлегендә яшәүчеләрнең җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруының башка рәвешләре һәм аны гамәлгә ашыруда катнашуы

1. Федераль законнар нигезендә әлеге Уставта каралган халык тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу рәвешләре белән беррәттән, гражданнар җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка рәвешләрдә катнашырга хокуклы.

2. Авыл җирлегендә яшәүчеләрнең җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруы һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы законлылык, ирекле лек принципларына нигезләнә.

Җирле үзидарә органнары һәм авыл җирлеге җирле үзидарәсе вазыйфаи затлары авыл җирлегендә яшәүчеләрнең җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруында һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуында халыкка ярдәм итәргә тиеш.

## III бүлек. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

### 29 маддә. Авыл җирлеге советы - авыл җирлеге җирле үзидарәсенең вәкиллекле органы

1. Авыл җирлеге Советы авыл җирлеге җирле үзидарәсенең даими эшләүче сайланулы коллегиаль вәкиллекле органы булып тора.

2. Авыл җирлеге советының рәсми исеме - "Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Советы". (Алга таба-авыл җирлеге советы).

3. Авыл җирлеге Советының вәкаләтләр срогы - 5 ел.

4. Авыл җирлеге Советы авыл җирлегендә яшәүчеләргә хисап тота һәм аларны контрольдә тота.

5. Авыл җирлеге Советының үз исеме язылган мөһере, бланклары бар.

6. Авыл җирлеге Советы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары авыл җирлеге бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

## 30 маддә. Авыл җирлеге Советы составы

1. Авыл җирлеге Советы бер мандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайлана торган 7 депутаттан тора.

2. Авыл җирлеге Советы аның составына авыл җирлеге Советының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән ике депутат сайланганда тулы хокуклы була.

## 31 маддә. Авыл җирлеге Советы депутаты статусы

1. Авыл җирлеге Советы депутаты вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш авыл җирлеге Советы эшли башлаган көннән туктатыла.

2. Авыл җирлеге Советы депутаты, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш, депутатлык эшчәнлеген төп эш урынындагы хезмәт һәм хезмәт бурычларын үтәү белән бергә алып барып, даими булмаган нигездә эшли.

3. Авыл җирлеге Советы депутаты статусына бәйле чикләүләр федераль законнар белән билгеләнә.

4. Авыл җирлеге Советы депутатына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав, авыл җирлеге Советы карарлары нигезендә үз вәкаләтләрен тоткарлыксыз гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин ителә.

5. Авыл җирлеге Советы депутаты авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана торган депутат этикасы кагыйдәләрен үтәргә тиеш, аларда депутатның түбәндәге йөкләмәләре булырга тиеш:

1) шәхсән үзенә яисә аның якын туганнарына кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен депутат статусыннан файдаланмаска;

2) депутат вазыйфаларын объектив үтәүдә үз-үзеңне шик тудырырлык тотудан тыелырга, шулай ук аның абруена яисә авыл җирлеге Советы абруена зыян китерерлек конфликтлы хәлләрдән качарга;

3) мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгу куркынычы булганда - шәхси кызыксыну депутат вазыйфаларын объектив үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясый алган вәзгыять булганда -  бу хакта авыл җирлеге советына хәбәр итәргә һәм аның әлеге мәнфәгатьләр конфликтын булдырмауга яисә җайга салуга юнәлдерелгән карарын үтәргә;

4) гавами чыгышларның авыл җирлеге Советында билгеләнгән кагыйдәләрен үтәргә;

5) Федераль закон нигезендә конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән, депутат бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа билгеле булган белешмәләрне депутат эшчәнлегенә бәйле булмаган максатларда фаш итмәскә һәм файдаланмаска;

6) депутат бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан (бүләкләр, акчалата бүләкләү, ссудалар, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачулар, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка бүләкләүләр) бүләкләр алмаска.

6. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны үтәргә тиеш. Депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләре "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, "Затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон,"Аерым категориядәге затларга счетлар (кертемнәр)ачуны һәм аларның керемнәре булуны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яисә) алардан файдалану буенча билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, бурычлар үтәлмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла..

7. Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары нигезендә авыл җирлеге Советы депутаты тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Рәисе карары белән Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

8. "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, "дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» ФЗ да билгеләнгән

чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Рәисе депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә күрсәтелгән затларга карата тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка җаваплылыкның башка чарасын куллану турындагы гариза белән мөрәҗәгать итә.

9. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары биналарда, махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук ишегалды территорияләре эчендә уздырыла, әгәр аларны үткәрү тормышны тәэмин итү объектларының, транспорт яки социаль инфраструктураның, элемтә объектларының эшләвен бозуга, җәяүлеләр һәм (яисә) транспорт чараларының хәрәкәтенә йә гражданнарның торак урыннарга яисә транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керүенә комачаулык тудыруга китермәсә. Мондый очрашулар турында Татарстан Республикасы Башкарма хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына хәбәр итү таләп ителми. Бу чакта депутат күрсәтелгән органнарга аларны үткәрү датасы һәм вакыты турында алдан хәбәр итәргә хокуклы.

10. Җирле үзидарә органнары депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус билгеләнгән урыннарны билгелиләр, шулай ук депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган биналар исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгелиләр.

11. Депутатның сайлаучылар белән гавами чара рәвешендәге очрашулары Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр һәм пикетлар турындагы законнары нигезендә үткәрелә.

12. Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнә торган гавами чара рәвешендә депутатның сайлаучылар белән очрашуларын оештыруга яисә уздыруга каршылык Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылыкка китерә.

## 32 маддә. Авыл җирлеге Советы депутатының сайлаучылар белән үзара мөнәсәбәте

1. Авыл җирлеге Советы депутаты сайлаучылар, шулай ук аның сайлау округы территориясендә урнашкан предприятиеләр, оешмалар коллективлары, дәүләт һәм башка органнар белән элемтәдә тора.

2. Авыл җирлеге Советы депутаты сайлаучылар алдында җаваплы һәм аларга хисап бирә.

3. Авыл җирлеге Советы депутаты сайлаучыларга елына кимендә бер мәртәбә үз эше турында хисап бирә, вакыт-вакыт аларга авыл җирлеге Советы эше турында хәбәр итә, шулай ук айга кимендә бер мәртәбә сайлаучыларны кабул итә.

4. Авыл җирлеге Советы депутаты авыл җирлегендә яшәүчеләрнең законлы хокукларын, ирекләрен һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча законнарда каралган чаралар күрергә, шул исәптән алардан кергән тәкъдимнәрне, гаризаларны, шикаятьләрне карарга, алардагы мәсьәләләрне дөрес һәм вакытында хәл итәргә ярдәм итәргә тиеш.

### 33 маддә. Яңа сайланган авыл җирлеге Советы эшен оештыру

1. Яңа чакырылыш авыл җирлеге Советы беренче утырышка депутатларның билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе сайланганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча җыела. Авыл җирлеге Советының сайлаулардан соң беренче утырышын авыл җирлеге башлыгы, ә ул булмаган очракта - муниципаль сайлаулар һәм җирле референдум үткәрү буенча авыл җирлеге сайлау комиссиясе чакыра.

2. Авыл җирлеге Советының сайлаулардан соңгы беренче утырышын авыл җирлеге Советының иң өлкән депутаты башлап җибәрә һәм алып бара.

### 34 маддә. Авыл җирлеге Советы компетенциясе

Авыл җирлеге Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) авыл җирлеге уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

2) авыл җирлеге территориясендә законнар нигезендә гомуми мәҗбүри кагыйдәләр билгеләү;

3) авыл җирлеге бюджетын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару, аларны түләү буенча Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә ташламалар бирү;

5) авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору турында инициатива күрсәтү;

6) авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү һәм авыл җирлеге Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау округлары схемасын раслау;

7) җирле референдумны билгеләү;

8) авыл җирлеге башлыгын сайлау;

9) авыл җирлеге башлыгы урынбасарын сайлау;

10) авыл җирлеге Советы депутатлары арасыннан авыл җирлеге вәкилен муниципаль район Советына сайлау;

11) авыл җирлеге Башкарма комитеты структурасын раслау, аның хезмәткәрләренең иң чик санын билгеләү;

13) авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, авыл җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне, авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү;

14) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Закон чыгару инициативасы хокукын гамәлгә ашыру;

15) авыл җирлеге муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибен, шул исәптән федераль законнар нигезендә аны хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү; авыл җирлеге Советы килештереп яисә раслаганнан соң читләштерелә торган муниципаль мөлкәт төрләре исемлеген билгеләү;

16) муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибен, шулай ук муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәт күрсәтүләренә, эшләр башкаруга тарифлар билгеләү тәртибен билгеләү, федераль законнарда каралган очраклардан тыш;

17) авыл җирлегенең муниципальара хезмәттәшлек оешмаларында катнашу тәртибен билгеләү;

18) җирле үзидарә органнары эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тәртибен билгеләү;

19) авыл җирлеге башлыгын отставкага җибәрү турында карар кабул итү;

20) җирле үзидарә органнарының һәм авыл җирлеге җирле үзидарәсе вазыйфаи затларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен үтәвен тикшереп тору;

21) авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар яши торган урамнарга, мәйданнарга һәм башка территорияләргә исемнәр бирү;

22) муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары бирү тәртибен билгеләү;

23) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарына авыл җирлеге бюджетыннан кирәкле акчалар бүлеп бирү шартларын һәм тәртибен билгеләү;

24) коммерциягә карамаган автономияле оешмалар һәм фондлар рәвешендә коммерциягә карамаган оешмалар төзү турында карарлар кабул итү;

25) авыл җирлеге Уставына һәм авыл җирлеге Советы карарларына аңлатма бирү;

26) үз эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча авыл җирлеге Советы Регламентын һәм башка карарлар кабул итү;

27) авыл җирлеге Советы аппараты турындагы нигезләмәне раслау;

28) авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын һәм авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын раслау, аларның таләпләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;

29) авыл җирлеген социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау;

30) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау;

31) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, авыл җирлегендә яшәүчеләргә рәсми мәгълүматны җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;

32) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән җирлекләрнең вәкиллекле органнары карамагына кертелгән башка вәкаләтләр, шулай ук әлеге устав белән авыл җирлеге Советы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләр.

2. Авыл җирлеге советы авыл җирлеге башлыгының аның эшчәнлеге, авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм авыл җирлеге башлыгы карамагындагы башка җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәләре, шул исәптән авыл җирлеге Советы куйган мәсьәләләрне хәл итү турында еллык хисапларын тыңлый.

## 35 маддә. Авыл җирлеге Советының эш тәртибе

1. Авыл җирлеге Советының эш тәртибе әлеге устав һәм авыл җирлеге Советы Регламенты белән билгеләнә.

2. Авыл җирлеге Советы эшенең төп формасы - аның утырышлары, аларда авыл җирлеге Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр хәл ителә.

3. Әгәр анда сайланган депутатларның кимендә 50 проценты катнашса, авыл җирлеге Советы утырышлары тулы хокуклы була.

4. Авыл җирлеге Советының чираттагы утырышлары кирәк булган саен, әмма кимендә өч айга бер мәртәбә үткәрелә. Чираттан тыш утырышлар авыл җирлеге башлыгы яисә депутатлар төркеме инициативасы белән авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санынынан кимендә өчтән бере чакырыла.

5. Совет утырышларын авыл җирлеге башлыгы чакыра. Авыл җирлеге Советы депутатларына һәм чакырылган затларга чираттагы утырышның вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында - биш көннән дә соңга калмыйча, ә чираттан тыш утырышның көн тәртибе турында уздырылырга бер көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

6. Авыл җирлеге Советы утырышлары ачык һәм ачыктан-ачык үткәрелә. Советның ачык утырышларында авыл җирлегендә яшәүче теләсә кайсы кеше катнашырга хокуклы.

Регламентта каралган очракларда авыл җирлеге Советы ябык утырыш үткәрү турында Карар кабул итәргә хокуклы, анда авыл җирлеге Советы тарафыннан чакырылган затлар гына, шулай ук закон нигезендә утырышта катнашырга хокуклы затлар гына катнаша ала.

7. Авыл җирлеге Советының һәр утырышында беркетмә алып барыла. Утырыш беркетмәсенә утырышны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында белешмәләр кертелә, карала торган барлык мәсьәләләр күчерелә һәм, тавыш бирү йомгакларын күрсәтеп, кабул ителгән барлык карарлар теркәлә. Авыл җирлеге Советы утырышы беркетмәсенә кул куелгач, авыл җирлеге башлыгы аның белән авыл җирлегендә яшәүче теләсә кайсы кеше таныша ала.

8. Авыл җирлеге Советы утырышларында һәр депутатның тавышы - бер тавыш. Авыл җирлеге Советы депутаты тавыш бирү хокукын шәхсән үзе гамәлгә ашыра. Авыл җирлеге Советы утырышларында тавыш бирү ачык (шул исәптән исемләп) һәм яшерен булырга мөмкин. Тавыш бирүнең һәр төрен куллану очраклары әлеге устав, авыл җирлеге Советы Регламенты белән билгеләнә.

### 36 маддә. Авыл җирлеге Советы эшчәнлеген оештыру

1. Авыл җирлеге Советы эшчәнлеген авыл җирлеге башлыгы оештыра.
2. Авыл җирлеге Советы Регламенты нигезендә авыл җирлеге Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен депутатлар арасыннан, авыл җирлеге башлыгыннан тыш, даими яисә вакытлы комиссияләр төзелергә мөмкин (яисә) күрсәтелгән мәсьәләләрне әзерләү өчен җаваплы депутатлар авыл җирлеге Советы эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча билгеләнергә мөмкин. Депутат ике даими комиссиядә эшләргә хокуклы.

3. Муниципаль программаларны, авыл җирлеге Советы карарлары проектларын әзерләү, авыл җирлеге карамагына кертелгән аеруча әһәмиятле мәсьәләләрне тикшерү өчен авыл җирлеге Советы каршында аның карары буенча депутатлар, авыл җирлеге Башкарма комитеты, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар һәм предприятиеләр вәкилләре, белгечләр, экспертлар һәм авыл җирлеге халкы составында эшче, эксперт һәм башка киңәшмә төркемнәре төзелергә мөмкин.

## 37 маддә. Авыл җирлеге Советы тарафыннан контроль функцияләрне гамәлгә ашыру

1. Авыл җирлеге советы авыл җирлеге территориясендә әлеге Устав нигезләмәләренең, авыл җирлеге Советы кабул итә торган норматив хокукый актларның үтәлешен, авыл җирлеге бюджеты үтәлешен, бюджеттан тыш фондлар акчаларыннан, авыл җирлеген үстерү программаларыннан файдалануны, авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлеген тикшереп тора.

2. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан законнарны, әлеге Уставны һәм башка муниципаль норматив хокукый актларны бозу фактлары ачыкланган очракта, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге башлыгы карары белән күрсәтелгән фактларны тикшерү өчен депутатлар арасыннан вакытлы контроль комиссияләр төзелергә мөмкин.

3. Законнар нигезендә авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге башлыгы инициативасы белән авыл җирлеге бюджеты акчаларыннан максатчан файдалануны, муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген тикшерүләр (ревизияләр) үткәрелергә мөмкин. Күрсәтелгән контроль һәм эксперт-аналитик чараларны үткәрү тәртибе гамәлдәге законнар белән билгеләнә.

4. Авыл җирлеге Башкарма комитеты, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, вазыйфаи затлар, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, әгәр законда башкасы билгеләнмәгән булса, авыл җирлеге Советы, аның контроль комиссияләре, авыл җирлеге Советы депутаты мөрәҗәгате буенча авыл җирлеге Советы карамагындагы мәсьәләләр буенча соратып алына торган мәгълүматны бирергә, ә законнар, муниципаль норматив хокукый актлар бозылган очракта кичекмәстән, хокук бозуларны бетерү чараларын күрергә һәм гаепле затларны җаваплылыкка тартырга тиеш.

5. Авыл җирлеге советы авыл җирлеге башлыгының аның эшчәнлеге, авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм җирле үзидарәнең ведомство буйсынуындагы башка органнары эшчәнлеге нәтиҗәләре, шул исәптән авыл җирлеге Советы куйган мәсьәләләрне хәл итү турында еллык хисапларын тыңлый.

6. Авыл җирлеге Советы, контроль функцияләрен башкарып, авыл җирлеге Башкарма комитетының финанс-хуҗалык һәм Башкарма-боерык бирү эшчәнлегенә

тыкшынырга хокуклы түгел.

## 38 маддә. Муниципаль район Советына авыл җирлеге вәкилен сайлау

1. Авыл җирлеге вәкиле авыл җирлеге Советы депутатлары арасыннан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына ачык тавыш бирү юлы белән сайлана.

2. Авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санынннан яртысыннан артыграгы яклап тавыш биргән кандидат сайланган дип санала.

## 39 маддә. Авыл җирлеге Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Авыл җирлеге Советының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылырга мөмкин, әгәр:

1) авыл җирлеге Советы тарафыннан үз-үзен таркату турында карар кабул ителгәндә;

2) "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 73 маддәсендә каралган тәртиптә һәм нигезләр буенча авыл җирлеге Советын таратканда;

3) авыл җирлеге Советы депутатларының әлеге составының хокуксызлыгы турында, шул исәптән депутатларның үз вәкаләтләрен тапшыруларына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Югары суды карары үз көченә кергәндә;

4) законнар нигезендә авыл җирлеген үзгәртеп корганда, шулай ук авыл җирлеге бетерелгән очракта;

5) авыл җирлеге чикләре үзгәрү яисә җирлекнең шәһәр округы белән берләшүе нәтиҗәсендә авыл җирлеге сайлаучылары санының 25 проценттан артуы;

6) гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерүе юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен таләп ителә торган муниципаль хокукый актны чыгару срогын бозу;

7) авыл җирлеге шәһәр округы белән берләшүгә бәйле рәвештә муниципаль берәмлек статусын югалткан очракта.

2. Авыл җирлеге Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату аның депутатлары вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуга китерә.

3. Авыл җирлеге Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта,

вакытыннан алда сайлаулар федераль законда билгеләнгән вакытларда уздырыла.

**40 маддә. Авыл җирлеге Советының үз-үзен таркату турында карар кабул итү тәртибе**

1. Авыл җирлеге советын үз-үзен таркату турындагы карар авыл җирлеге башлыгы яисә авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан ким булмаган депутатлар төркеме инициативасы белән кабул ителергә мөмкин.

2. Үз-үзен таркату турында карар кабул итү инициативасы тәкъдим ителә алмый:

1) авыл җирлеге Советы сайланганнан соң беренче ел дәвамында;

2) авыл җирлеге бюджетын кабул итү һәм аның үтәлеше турында хисапны раслау чорында;
3) авыл җирлеге башлыгын чакыртып алу турында тавыш бирү чорында йә аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта.

3. Авыл җирлеге Советының үз-үзен таркату турындагы язма тәкъдимендә үз-үзен таркату мотивлары булырга тиеш, шулай ук аңа үз-үзен таркату сәбәпләрен дәлилләүче башка материаллар да кушып бирелергә мөмкин.

4. Депутатлар арасыннан үз-үзен таркату турындагы мәсьәләне алдан карау өчен авыл җирлеге Советы карары белән комиссия төзелә. Авыл җирлеге Советы яки авыл җирлеге башлыгы карары белән авыл җирлеге Советының үз-үзен таркату мәсьәләсе гавами тыңлауларга чыгарылырга мөмкин.

5. Авыл җирлеге Советының үз-үзен таркату мәсьәләсен карауның дәвамлылыгы авыл җирлеге Советы депутатлары һәм авыл җирлеге халкы тарафыннан үз-үзен таркату инициативасының барлык шартлары һәм Нигезләмәләре турында һәрьяклы һәм объектив фикер алышу мөмкинлеген гарантияләргә тиеш. Үз-үзен таркату турындагы карар үз-үзен таркату турындагы инициатива күрсәтелгән көннән соң ике ай узгач кабул ителергә мөмкин.

6. Авыл җирлеге Советын үз-үзен таркату турындагы карар авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санынннан өчтән ике өлеше тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

7. Авыл җирлеге Советы үз-үзен таркату турындагы тәкъдимне кире каккан очракта, кабат инициатива, үз-үзен таркату турындагы мәсьәлә буенча тавыш биргән көннән кимендә бер ел узгач күрсәтелергә мөмкин.

**41 маддә. Авыл җирлеге Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Авыл җирлеге Советы депутатының вәкаләтләре түбәндәге очракта вакытыннан алда туктатыла:

1) вафат булган;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яисә эшкә сәләте чикләнгән дип тану;

4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылса яисә вафат дип игълан ителсә;

5) аңа карата судның гаепләү хөкеме законлы көченә керсә;

6) даими яшәү урынына Россия Федерациясеннән читкә китү;

7) Россия Федерациясе гражданлыгын йә чит дәүләт гражданлыгын туктату - чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының чит дәүләт гражданлыгы (гражданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының йә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;

8) сайлаучылар тарафыннан чакыртып алынган;

9) авыл җирлеге Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

10) хәрби хезмәткә чакырылу яисә аны алмаштыручы альтернатив граждан хезмәтенә җибәрү;

11) федераль законнарда билгеләнгән башка очракларда.

